СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«МУКМИН-КАРАТАЙСКОЕ
СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»
ЛЕНИНОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«МӨЭМИН-КАРАТАЙ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

Мөэмин-Каратай ав

2025 елның 08 июле № 15

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Мөэмин-Каратай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының «Җир салымы турында 2020 елның 15 октябрендәге 7 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында (02.11.2023 №43, 06.06.2024 №11 үзгәрешләр белән)

Россия Федерациясе Салым кодексының 394 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Мөэмин-Каратай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Мөэмин-Каратай авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1.Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы " Мөэмин-Каратай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2025 елның 23 июнендәге 14 номерлы "Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Мөэмин-Каратай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының «Җир салымы турында» 2020 елның 15 октябрендәге 7 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» (02.11.2023 №43, 06.06.2024 № 11 үзгәрешләр белән) карарын гамәлдән чыгарырга.

2.Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Мөэмин-Каратай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының «Җир салымы турында» 2020 елның 15 октябрендәге 7 номерлы карарына (02.11.2023 ел, № 43, 06.06.2024 ел, № 11 үзгәрешләрне кертеп) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

2 пунктның өченче һәм дүртенче абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"-0,3% торак фонды һәм (яисә) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары биләгән җир кишәрлекләренә карата (торак фондына һәм (яисә) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектларына карамаган күчемсез мөлкәт объектына туры килә торган җир кишәрлегенең өлешеннән тыш) яисә торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләренә карата, моңа әлеге абзацта күрсәтелгән индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән), эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланыла торган җир кишәрлекләре һәм һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып китә торган җир кишәрлекләре;

«-0,25% шәхси ярдәмче хуҗалык, бакчачылык яисә яшелчәчелек алып бару өчен сатып алынган (бирелгән) эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланылмый торган җир кишәрлекләренә, шулай ук «Гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып баруы турында һәм Россия Федерациясе аерым актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы Федераль законда каралган гомуми билгеләнештәге җир кишәрлекләре, әлеге абзацта һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып китә торган җир кишәрлекләреннән тыш;".

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Мөэмин-Каратай авылы, Механизаторлар ур., 31Б йорт адресы буенча урнашкан җирлекнең мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә һәм Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында

(https://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар Россия Федерациясе Салым кодексының 5 статьясы нигезендә үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы
«Мөэмин-Каратай авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге урынбасары З.Р.Шәрапова